ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 24.03.2023 348 **КАРАР**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль
районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә
белем бирү программасын гамәлгә ашыручы
мәгариф оешмаларына йөрүче балалары
булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын
күрсәтү турында» елның 26 сентябрендәге
1101 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дарулар сатып алуга түләү турында» 2019 елның 12 декабрендәге 1095 номерлы карары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» елның 26 сентябрендәге 1101 номерлы карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
   1.1. Тәртипнең 1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
   «1.3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дарулар сатып алуга түләү турында» 2019 елның 12 декабрендәге 1095 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 февралендәге 100 номерлы карары үзгәрешләре белән) белән расланган, гаиләнең җан башына туры килә торган уртача керемен компенсацияләү хокукын билгеләгәндә, кагыйдәләр нигезендә исәпләнә.
   1.2. Тәртипнең 2.1 пунктындагы 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
   «Мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының гариза тапшырылган айга кадәр алты календарь аеннан алда

соңгы 12 календарь ае өчен керемнәрен раслый торган документлар»

1.3. Тәртипнең 2.1 пунктындагы 4 абзацын төшереп калдырырга.

1.4. Тәртипнең 2.2 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар булу (булмау) турында белешмәләр»

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары Н.Д. Курамшинга йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 00FBD291B1574C09AAA1CBD7F6C923D025
Владелец: Исланов Роман Леонидович
Действителен с 14.03.2023 до 06.06.2024

Р.Л. Исланов